РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
КЛЯШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЕЛӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 56-0-39, факс 56-0-39

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**31 .10. 2022** **№ 1**

**2023 елда үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегенең Тоншерма торак пунктында Гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Кляшево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 10 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Тоншерма авылы, Ленин ур., 57 йорт адресы буенча урнашкан Тоншерма авылы мәдәният йорты бинасында, 2023 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләп кую.

2. 2022 елның 10 ноябрендә Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Тоншермә авылы, Ленин ур., 54 адресы буенча урнашкан Тоншермә урта мәктәбе бинасы янындагы урамда 10 сәгать 30 минутка билгеләргә.

3. 2022 елның 10 ноябрендә Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Тоншермә авылы, Ленин урамы, 57 нче йорт адресы буенча урнашкан Тоншермә авылы мәдәният йорты бинасында 12 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегендә яшәүчеләр исемлеген бүлүне сайлау тәртибен вакытлыча билгеләр буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегенең Тоншермә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы?:

-Тоншерма торак пунктындагы буаны чистарту эшләрен үткәрү өчен проект-смета документларына экспертиза ясау(эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

- Тоншерм торак пунктындагы буаны чистарту (Эш, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)?»

"РИЗА" "КАРШЫ"

6. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм үткәрергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегенең информацион стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/ .

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **Ф.Х. Галимов**